**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 14 апрель № 223

г. Казань

Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында

Татарстан Республикасы Президентының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясен гамәлгә кую турында» 2016 елның 14 мартындагы ПУ-140 нчы Указын үтәү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе комитетын булдырырга.

2. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында нигезләмә;

Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе комитеты составын.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы» ведомствосы буенча Г.Р.Державин исемендәге республика премиясен түләүгә 400,0 мең сум күләмендә акча карарга.

4. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе комитеты эше нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 14 апрель, 223 нче
карары белән расланды

## Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе (алга таба – премия) соңгы өч елда басылып чыккан әдәбият (шигърият, проза, әдәби тәрҗемә) өлкәсендә күренекле әсәрләре һәм юриспруденция өлкәсендә фәнни тикшеренүләре өчен (алга таба – эшләр) язучыларга, шагыйрьләргә, тәрҗемәчеләргә, юристларга бирелә.

2. Премия елга бер тапкыр, һәрберсе 200 сум күләмендә ике премия рәвешендә бирелә.

3. Премия алган затларга «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе лауреаты» исеме бирелә, диплом, лауреат билгесе, билгеләнгән үрнәктәге таныклык һәм акчалата бүләк тапшырыла.

4. Премия алуга аерым авторлар, шулай ук авторлар коллективы башкарган эшләр чыгарыла.

Авторлар коллективы бастырып чыгарган эшләрне премия алуга чыгарган очракта диплом, лауреат билгесе һәм таныклык лауреатларның һәрберсенә тапшырыла, ә акчалата бүләк түбәндәге рәвештә бүленә:

өч кешелек авторлар коллективында коллектив җитәкчесенә акчалата бүләкнең яртысы бирелә, ә икенче яртысы коллективның калган ике әгъзасы арасында тигез итеп бүленә;

ике автор булганда акчалата бүләк алар арасында тигез өлешләргә бүленә;

дүрт яки аннан күбрәк кеше булган коллективта коллектив җитәкчесенә акчалата бүләкнең өчтән бере бирелә, ә өчтән икесе коллективның калган әгъзалары арасында тигез өлешләргә бүленә;

әгәр авторлар коллективы җитәкчене аерып чыгармаса, акчалата бүләк коллективның барлык әгъзалары арасында тигез өлешләргә бүленә.

Премия алуга үлгәннән соң чыгару рөхсәт ителә.

Үлгәннән соң бүләкләнгән яки үлгән лауреатның дипломы, лауреат билгесе, таныклыгы һәм акчалата бүләк аның гаиләсенә истәлек буларак тапшырыла яки кала, ә акчалата бүләк Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мирас буенча тапшырыла.

5. Премияне Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе комитеты (алга таба – Комитет) рәисе ел саен 14 июльдә тапшыра.

### II. Премия алуга эшләрне чыгару тәртибе

6. Премия алуга эшләрне чыгару Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары, учреждениеләр һәм оешмалар (шул

исәптән югары белемнең мәгариф оешмалары, театрлар, музейлар, мәдәни-ял учреждениеләре, иҗтимагый оешмалар), җирле үзидарә органнары (алга таба – оешма) тарафыннан башкарыла.

Эшләр коллегияләр, президиумнар, секретариатлар, гыйльми һәм әдәби советлар утырышларына, хезмәт коллективлары һәм оешманың бүтән коллегиаль органнары җыелышларына чыгарыла.

7. Һәр эш премия алуга ике тапкырдан артык чыгарылмый.

8. Премия алуга материаллар карап тикшерү өчен Комитетка ел саен, 23 майга кадәр 420015, Казан ш., Пушкин ур., 66/33 йорт адресы буенча тапшырыла.

9. Премия алу өчен оешма Комитетка авторның (авторлар коллективының) фамилиясе, исеме, әтисе исеме, эшнең тулы исеме күрсәтелгән заявканы, өч данәдә бастырылган эшне тапшыра.

10. Эшне чыгару турында заявка белән бергә оешмалар түбәндәгеләрне тапшыра:

Оешманың эшне чыгару турында коллегиаль карары (коллегия, утырыш, әдәби һәм гыйльми совет, хезмәт коллективы җыелышы беркетмәсе);

премия алырга теләүченең шәхси мәгълүматлары һәм иҗади бәяләмәсе кергән анкетасы, авторның ике фотосы (6 х 9 см);

тапшырылган эшнең кыскача аннотациясе;

эшне башкаруга авторның (авторлар коллективының) керткән өлешен бәяләүче материал;

тиешле өлкәдә (әдәбият һәм юриспруденция) белгечнең тышкы тышкы бәяләмәсен.

Барлык материаллар эшне премия алуга чыгара торган оешма тарафыннан таныклана. Бер оешма берничә эшне чыгарганда аларның һәрберсенә аерым заявка төзелә.

11. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вакытлары бозылып җибәрелгән заявкалар дәгъва кылуда катнашмый.

Әгәр заявкага әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлмәсә, автор (авторлар коллективы) әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында билгеләнгән вакыт үткәнче җитмәгән документларны тапшырырга хокуклы.

12. Конкурста катнашу рөхсәт ителгән эшләр массакүләм мәгълүмат чараларында, авторлар эшләрен чыгара торган оешмаларда фикер алышулар уза. Комитет конкурста катнашу рөхсәт ителгән эшләр турында фикер алышулар оештыра.

## III. Премия алу өчен эшләрне сайлап алуның төп критериеләре

13. Премия алу өчен эшләрне сайлап алуның түбәндәге төп критериеләре билгеләнә:

әсәрнең югары әдәби яки гыйльми дәрәҗәсе (әлеге өлкәдә белгечнең тышкы рецензиясе) (0 – 10 балл);

иҗтимагый фикернең уңай бәяләмәсе (ММЧда иҗтимагый фикер алышу материалларын чыгару нигезендә) (0 – 10 балл);

Татарстан Республикасында әдәбият һәм юриспруденцияне үстерү өчен эшнең актуальлеге һәм әһәмиятлелеге (0 – 10 балл).

## IV. Комитет эшчәнлеген оештыру һәм премия бирү турында карар кабул итү тәртибе

14. Комитет составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана. Комитет мәдәният, фән, мәгариф эшлеклеләре, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре арасыннан формалаша.

15. Комитетка түбәндәгеләр йөкләнә:

конкурс игълан итү һәм үткәрү;

конкурс эшләре кабул итү һәм карап тикшерү (бәяләү), сайлап алу;

бүләкләү документларын рәсмиләштерү һәм тапшыру, премияләр түләү.

16. Комитет әгъзалары конкурста катнашмый.

17. Комитет утырышлары, аларда составының өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы санала.

18. Премия бирү турында карар ачык тавыш бирү юлы белән Комитет утырышында катнашучы Комитет әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә, беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Әгәр Комитет әгъзалары тавыш бирүе нәтиҗәләре баллары саны тигез булса, Комитет рәисе хәлиткеч тавыш хокукына ия.

Комитет утырышы йомгаклары буенча мәгълүмат нәтиҗәләрне рәсми игълан иткәннән соң, Г.Р.Державин туган көнендә (14 июль) Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтында (http://mincult.tatarstan.ru) урнаштырыла .

19. Премия бирү белән бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 14 апрель, 223 нче
карары белән расланды

**Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Шәйхрәзиев Васыйл Габтелгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Комитет рәисе |
| Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры – Комитет рәисе урынбасары |
| Глухова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы юстиция министры – Комитет рәисе урынбасары |
| Афанасьев Михаил Павлович | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Вәлиев Разил Исмәгыйль улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстан Республикасы халык шагыйре (килешү буенча) |
| Гафуров Илшат Рәфкать улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары һөнәри белем учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Гревцов Андрей Борисович | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы |
| Демидов Виктор Николаевич | Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Зарипов Айрат Ринат улы | «Татмедиа» республика басма һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Корбанов Рәфис Харис улы | Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Фәттахов Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Ратникова Римма Атлас кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Сәлахов Мәкъзүм Хәлимулла улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (килешү буенча) |
| Терентьев Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президент Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе (килешү буенча). |